**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КИЛЬДЮШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422387 с. Кильдюшево, ул. Молодёжная, 22

422387 Килдеш авылы, Яшьләр урамы, 22

тел. (84373) 5-22-66,e-mail: Kld.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559325, ИНН/КПП 1638001590/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**06.12. 2022** **№ 21-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1 Статья

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетының фаразлана торган гомуми керем күләме 1650,53 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең бюджет чыгымнарының гомуми күләме 1650,53 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең бюджет дефициты 0,00 мең сум.

2. 2024 елга һәм 2025 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 1677,08 мең сум һәм 2025 елга 1725,25 мең сум күләмендә фаразлана;

2) 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1677,08 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-38,60 мең сум һәм 2025 елга 1725,25 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-79,40 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең 2024 елга 0,00 мең сум һәм 2025 елга 0,00 мең сум күләмендә бюджет дефициты.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының югары чиген дә.

2. 2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының югары чиген дә.

3. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының югары чиген дә.

3 Статья
Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетында 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья
1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга
2. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең бюджет чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.
3. 2023 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга, 2024 елга 0,00 мең сум һәм 2025 елга 0,00 мең сум күләмендә.
5 Статья
Юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), шәхси эшмәкәрләргә һәм товар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) җитештерүче физик затларга субсидияләр Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 Статья
Тышкы муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бүтән бюджетара трансфертлар күләмен расларга:
2023 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2024 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2025 елга 1,00 мең сум күләмендә.

7 Статья
Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алынган акчаларны исәпкә алырга
1) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2023 елга-682,4 мең сум;
2024 елга-681,9 мең сум күләмендә;
2025 елга-711,1 мең сум.
2) хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр:
2023 елга-126,43 мең сум күләмендә;
2024 елга-132,38 мең сум күләмендә;
2025 елга-137,25 мең сум.

8 Статья
Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2023 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга

китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 Статья
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары, төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

10 Статья
Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 Статья
Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **В.С. Исаев**